**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**СОВЕТЫ**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 47** **2019 елның 25 июле**

Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату һәм билгеләү өчен тиешле күләмдә түләү тәртибе турында» 2012 елның 24 февралендәге 18 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату һәм билгеләү өчен тиешле күләмдә түләү тәртибе турында» 2012 елның 24 февралендәге 18 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 нче кушымтада:

1 пунктка «Россия Федерациясе Җир кодексының V. 7 бүлегендә каралган очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

3 пунктта:

1 пунктчага «, шул исәптән гомуми кулланылыштагы су объекты янына һәм аның яр буе полосасына гражданнарның иреклe үтеп керүен тәэмин итү максатларында» сүзләрен өстәргә;

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җир кишәрлегендә дәүләт геодезия челтәрләренең межалау билгеләре, геодезия пунктлары, гравиметрик пунктлар, нивелир пунктлары һәм аларга керү юллары урнаштыру;»;

8 пунктчага «, аквакультура (балык үрчетү)» сүзләрен өстәргә;

3 пунктның 2, 9,10 пунктчалары үз көчен югалткан дип танырга;

16 пунктның беренче абзацында «җир кишәрлегенең кадастр паспортына» сүзләрен «Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктның өченче абзацында «Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешкә хокукның бердәм дәүләт реестрында» сүзләрен «Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче кушымтада:

1.1 пунктына «Россия Федерациясе Җир кодексында яки федераль законда каралган очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктында «Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешкә хокукның бердәм дәүләт реестрында» сүзләрен «Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында» сүзләренә алмаштырырга.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы

А.Р. Метшин